**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость,
423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте
авылы, 423104

ИНН 1640003989 тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

№2 30.01.2023 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерының хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 9 августындагы 03-16/5605 номерлы карары белән, авыл җирлегенең баш бухгалтерына социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 24 апрелендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтерының хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 «Шешминка авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы нигезләмәләр» 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Баш бухгалтерның вазыйфаи окладты 19700,00 сум (Унтугыз мең җиде йөз сум) күләмендә

билгеләнә».

2. Әлеге карар нигезендә, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калганда һәм алар тарафыннан шул ук квалификацияне үтәгәндә, хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме 2022 елның 31 декабренә түләнә торган хезмәт хакыннан ким була алмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

М.Д.Шәйхетдинов